**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменения в статью 1 Закона Республики Татарстан «Об установлении налоговой ставки по налогу на прибыль организаций для отдельных категорий налогоплательщиков»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
20 февраля 2020 года

## Статья 1

Внести в пункт 1 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 2 августа 2008 года № 53-ЗРТ «Об установлении налоговой ставки по налогу на прибыль организаций для отдельных категорий налогоплательщиков» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2008, № 8 (I часть); 2009, № 6; 2011, № 5, № 11 (I часть); 2012, № 11 (I часть); 2013, № 10; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 19 (часть I) изменение, изложив его в следующей редакции:

«1) для субъектов инвестиционной деятельности, созданных после вступления в силу настоящего Закона с целью реализации инвестиционных проектов в соответствии с Законом Республики Татарстан от 25 ноября 1998 года № 1872 «Об инвестиционной деятельности в Республике Татарстан» и не осуществляющих иной деятельности, не связанной с реализацией инвестиционных проектов, а также для субъектов инвестиционной деятельности, заключивших договоры о реализации инвестиционных проектов в порядке и в соответствии с указанным Законом до вступления в силу настоящего Закона.

Субъект инвестиционной деятельности в период действия договора о реализации инвестиционного проекта вправе применить налоговую ставку в соответствии с настоящим пунктом по итогам налогового периода при соблюдении следующих условий:

выполнение условий, предусмотренных бизнес-планом;

уплата в консолидированный бюджет Республики Татарстан в отчетном году совокупной суммы налога на прибыль организаций, налога на доходы физических лиц, налога на имущество организаций, транспортного налога, земельного налога и суммы соответствующих пеней и штрафов (с исключением влияния изменений сумм недоимки по налогам, задолженности по пеням и штрафам и сумм излишне

уплаченных или излишне взысканных налогов (пеней, штрафов) в части налога на прибыль организаций и налога на имущество организаций) в размере не менее среднеарифметического значения сумм фактической уплаты субъектом инвестиционной деятельности соответствующих налогов (пеней, штрафов) (в сопоставимых условиях в части применения налоговых льгот) за три года, предшествующих отчетному году (либо за иной период, предшествующий отчетному году, но не более двух лет, с учетом момента создания субъекта инвестиционной деятельности и с учетом абзаца шестого настоящего пункта), проиндексированных по итогам каждого года на показатель изменения суммы поступлений налогов в консолидированные бюджеты субъектов Российской Федерации в целом по Российской Федерации по соответствующей отрасли, определяемый на основании данных отчета о начислении и поступлении налогов, сборов и страховых взносов в бюджетную систему Российской Федерации по основным видам экономической деятельности за соответствующий год, представляемого по форме, утверждаемой федеральным органом исполнительной власти, уполномоченным по контролю и надзору в области налогов и сборов;

представление согласия на предоставление налоговым органом в финансовый орган Республики Татарстан сведений о суммах начисленных и уплаченных субъектом инвестиционной деятельности налогах, суммах недоимки по налогам, задолженности по пеням и штрафам и суммах излишне уплаченных или излишне взысканных налогов (пеней, штрафов), суммах полученных налоговых льгот в разрезе льгот.

Вновь созданный субъект инвестиционной деятельности вправе применить налоговую ставку в соответствии с настоящим пунктом без соблюдения условия, установленного абзацем четвертым настоящего пункта, по итогам первого налогового периода по налогу на прибыль организаций.

Право на применение налоговой ставки в соответствии с настоящим пунктом возникает начиная с отчетного периода по налогу на прибыль организаций, следующего за отчетным периодом, в котором заключен договор о реализации инвестиционного проекта.

Порядок и методика оценки соблюдения субъектом инвестиционной деятельности условия применения налоговой ставки в соответствии с настоящим пунктом, предусмотренного абзацем четвертым настоящего пункта, утверждаются Кабинетом Министров Республики Татарстан. Такой порядок должен содержать в том числе методику расчета показателя изменения суммы поступлений налогов в консолидированные бюджеты субъектов Российской Федерации в целом по Российской Федерации по соответствующей отрасли;».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу по истечении одного месяца со дня его официального опубликования, но не ранее первого числа очередного налогового периода по налогу на прибыль организаций.

2. Положения пункта 1 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 2 августа 2008 года № 53-ЗРТ «Об установлении налоговой ставки по налогу на прибыль

организаций для отдельных категорий налогоплательщиков» (в редакции настоящего Закона) применяются к договорам о реализации инвестиционных проектов, заключенным после 1 января 2021 года.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
07 марта 2020 года
№ 7-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 8 (I өлеш); 2009, № 6; 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1) «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатында әлеге Закон үз көченә кергәннән соң төзелгән һәм инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга бәйле булмаган башка эшчәнлекне гамәлгә ашырмый торган инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен, шулай ук әлеге Закон үз көченә кергәнче күрсәтелгән Закон тәртибендә һәм нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында шартнамәләр төзегән инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен.

Инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамәнең гамәлдә булу чорында инвестиция эшчәнлеге субъекты әлеге пунктта каралган салым ставкасын салым чоры йомгаклары буенча түбәндәге шартларны үтәгәндә кулланырга хокуклы:

бизнес-планда каралган шартлар үтәлү;

хисап елында Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына оешмалар табышына салымның, физик затлар кеременә салымның, оешмалар мөлкәтенә салымның, транспорт салымының, җир салымының кушма суммалары һәм тиешле пенялар һәм штрафлар суммалары (салымнар буенча недоимка, пенялар

һәм штрафлар буенча бурычлар суммаларының һәм оешмалар табышына салым һәм оешмалар мөлкәтенә салым өлешендә артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнар (пенялар, штрафлар) суммаларының үзгәрешләре йогынтысын исәпкә алмыйча) хисап елына кадәрге өч ел өчен булып (яисә, инвестиция эшчәнлеге субъекты төзелгән вакытны исәпкә алып һәм әлеге пунктның алтынчы абзацын исәпкә алып, хисап елына кадәрге башка чор өчен, ләкин ике елдан күбрәк түгел), тиешле тармак буенча тулаем Россия Федерациясендә Россия Федерациясе субъектларының берләштерелгән бюджетларына салымнардан кергән акчалар суммасы үзгәрү күрсәткеченә, ул салымнар һәм җыемнар өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган форма буенча тапшырыла торган тиешле ел өчен икътисадый эшчәнлекнең төп төрләре буенча Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре исәпләп бирелү һәм түләнү турындагы хисап белешмәләренә нигезләнеп билгеләнә, һәр ел йомгаклары буенча индексацияләнгән тиешле салымнарның (пеняларның, штрафларның) (салым ташламаларыннан файдалану өлешендә чагыштырма шартларда) инвестиция эшчәнлеге субъекты тарафыннан чынбарлыкта түләнгән суммаларының уртача арифметик күрсәткеченнән ким булмаган күләмдә түләнү;

Татарстан Республикасы финанс органына инвестиция эшчәнлеге субъектына исәпләп бирелгән һәм аның тарафыннан түләнгән салымнар суммалары, салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар суммалары һәм артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнар (пенялар, штрафлар) суммалары, бирелгән салым ташламаларының ташламалар киселешендәге суммалары турында белешмәләрне салым органы тарафыннан бирүгә ризалык бирелгән булу.

Яңа төзелгән инвестиция эшчәнлеге субъекты салым ставкасын оешмалар табышына салым буенча беренче салым чоры йомгаклары буенча, шушы пунктның дүртенче абзацында билгеләнгән шартны үтәмичә, әлеге пункт нигезендә кулланырга хокуклы.

Салым ставкасын әлеге пункт нигезендә куллану хокукы инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә төзелгән хисап чорыннан соң килүче оешмалар табышына салым буенча хисап чорыннан башлап барлыкка килә.

Салым ставкасын әлеге пункт нигезендә кулланының шушы пунктның дүртенче абзацында билгеләнгән шартының инвестиция эшчәнлеге субъекты тарафыннан үтәлүен бәяләү тәртибе һәм методикасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана. Мондый тәртиптә тиешле тармак буенча тулаем Россия Федерациясендә Россия Федерациясе субъектларының берләштерелгән бюджетларына салымнардан кергән акчалар суммасы үзгәрү күрсәткечен исәпләп чыгару методикасы булырга тиеш;».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән бер ай узгач, ләкин оешмалар табышына салым буенча чираттагы салым чорының беренче числосыннан да иртәрәк түгел, үз көченә керә.

2. «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2008 елның 2 августындагы 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) 2021 елның 1 гыйнварыннан соң төзелгән инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турындагы шартнамәләргә карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 07 март
№ 7-ТРЗ